| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
| --- | --- | --- |

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
| --- | --- | --- |
| 17.08.2022 | г. Казань | № 131-10/т-2022 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә шәһәр яны элемтәсендә даими ташуларның муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуның иң чик максималь тарифларын билгеләү турында» 05.10.2018 №7-9/т карарына үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2022 елның 25 июлендәге 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 17 августындагы утырышының 22-ПР номерлы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә шәһәр яны элемтәсендә даими ташуларның муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуның иң чик максималь тарифларын билгеләү турында» 05.10.2018 № 7-9/т карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

преамбулада «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль законны гамәлгә ашыру турында» федераль законны гамәлгә ашыру турында» сүзләрен «Татарстан Республикасында

автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев